ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 декабрь, 2017 ел № 21/15

Шәһәр урамнарына һәм тыкрыгына
исем бирү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законының 16 маддәсе, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе нигезендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең топонимика буенча Комиссиясе тәкъдимен карап,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Исем бирергә:

1) 50А микрорайон җирлегендәге шәхси йортлар районында Иван Можаров тыкрыгына тоташкан тупикка, 1 кушымтадагы карта-схемада каралганча, «Иван Можаров тыкрыгы» исемен бирергә;

2) Суар торак районындагы урамнарга, 2 кушымтадагы карта-схемада каралганча, «Дамир Бәдретдинов урамы», «Виктор Герасименко урамы» исемнәрен бирергә;

3) 6 квартал торак районындагы урамга, 3 кушымтадагы карта-схемада каралганча, «Виктор Дериглазов урамы» исемен бирергә.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев